**СОВЕТ**
**НОВОКИНЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЯҢА КЕНӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

улица Советская, д.10, с.Новый Кинер,
Арский муниципальный район, 422031

Совет урамы, 10 нче йорт, Яңа Кенәр авылы, Арча
муниципаль районы, 422031

Тел.,факс (84366)9-12-65, (84366)9-12-68, 9-12-60. E-mail: Nkin.Ars@tatar.ru

**Яңа Кенәр авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**«19» октябрь 2020 ел** **№ 10**

**Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясына яраклаштырып, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кенәр авыл җирлеге башкарма комитетының «Референдум үткәрүдә инициатива күрсәтү турында» 2020 елның 15 октябрендәге 31 номерлы карары, Яңа Кенәр авыл җирлеге Советының «Референдум үткәрүдә инициатива күрсәтү турында» 2020 елның 15 октябрендәге 9 номерлы карары нигезендә Яңа Кенәр авыл җирлеге Советы **КАРАР** бирде:

1. 2020 елның 06 декабренә Яңа Кенәр авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:
"2021 елда сез Яңа Кенәр авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, түләү күләме 150 сум тәшкил иткән Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, 1 нче Төркем инвалидлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, балачак инвалидларыннан, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылар, Чернобыль АЭСдәге аварияне бетерүдә катнашучылардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле

әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме:

| № | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең исеме | Планлаштырылган чаралар |
|---|---|---|
| 1 | Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында юл эшчәнлеге | 1.Яңа Кенәр авылында автомобиль юлларын вак таш җәеп тигезләү:<br>- Татарстан ур.;<br>- Киров ур.;<br>- Ямашев ур.;<br>- Комсомол ур.<br>2. Юл полотносының нигезен салу һәм вак таш җәю:<br>Яңа Кенәр – Урак һәм Чүкеч урамыннан – Ленин урамына баруның 1 нче юлы (150 м)<br>Яңа Ашыт – Вахитов ур. (100 м)<br>Шурабаш - Тынычлык ур. (280 м)<br>- Гагарин ур. (71 м)<br>Шура - Яна Әлиф ур. (200 м)<br>Байкал - Тука ур. (203 м)<br>Яңа Сәрдә - Һ.Такташ ур. (109 м)<br>Сөрде -Совет ур. (100 м)<br>- Киров ур. (214 м)<br>Югары Оры -Киров ур. (196 м)<br>Түбән Оры - Җиңү ур. (50 м)<br>- Г.Гафиятуллин ур. (50 м)<br>- Тукай ур. (148 м)<br>Кызыл-Яр - Нариман ур. (30 м)<br>- Киров ур. (75 м)<br>- Тукай ур. (40 м) |
| 2 | Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру | 1. Балалар мәйданчыгы сатып алу һәм Яңа Кенәр авылында урнаштыру (1 данә);<br>2. Яңа Кенәр авылы,1 Май урамындагы зиратны киртәләп алу өчен материал сатып алу һәм киртәләү(285 м);<br>3.Яңа Кенәр авылына керү юлына аншлаг (композиция) кую. |

3.Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә рөхсәт итәргә.

«ӘЙЕ» «ЮК».

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының Рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга һәм халык күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына түбәндәге адреслар буенча урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Арча районы, Яңа Кенәр авылы, Совет урамы, 10 йорты; Татарстан Республикасы, Арча районы, Сөрде авылы, Совет урамы, 48 йорты; Татарстан Республикасы, Арча районы, Шурабаш авылы, Гагарин урамы, 17 А йорты.

4. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Яңа Кенәр авыл җирлеге башлыгы                Фәхретдинов Р.Ә.

СОВЕТ НОВОКИНЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ